**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 октябрь № 812

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәт өчен түләүләре Бердәм тариф челтәре нигезендә хисаплап чыгарыла торган Татарстан Республикасы бюджетыннан финансланучы оешмалар хезмәткәрләренә эш хакын арттыру турында» 2011 ел, 14 июнь, 477 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәт өчен түләүләре Бердәм тариф челтәре нигезендә хисаплап чыгарыла торган Татарстан Республикасы бюджетыннан финансланучы оешмалар хезмәткәрләренә эш хакын арттыру турында» 2011 ел, 14 июнь, 477 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 19 октябрь, 870 нче; 2012 ел, 6 ноябрь, 966 нчы; 2013 ел, 17 октябрь, 767 нче; 2013 ел, 31 декабрь, 1104 нче; 2014 ел, 16 октябрь, 762 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктның беренче абзацындагы «2014 елның 1 октябреннән» сүзләрен «2015 елның 1 октябреннән » сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карарга теркәлгән 1 һәм 3 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәләләр).

2. Бу карарның гамәле 2015 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\812.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2011 ел, 14 июнь, 477 нче
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 30 октябрь, 812 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары)

| Бердәм тариф челтәренең түләү разрядлары | Тариф коэффи-циент-лары | Тариф ставкалары (окладлары), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,0 | 2239 |
| 2 | 1,047 | 2344 |
| 3 | 1,09 | 2440 |
| 4 | 1,142 | 2557 |
| 5 | 1,268 | 2839 |
| 6 | 1,407 | 3150 |
| 7 | 1,546 | 3461 |
| 8 | 1,699 | 3804 |
| 9 | 1,866 | 4177 |
| 10 | 2,048 | 4585 |
| 11 | 2,241 | 5018 |
| 12 | 2,423 | 5426 |
| 13 | 2,617 | 5860 |
| 14 | 2,813 | 6298 |
| 15 | 3,035 | 6796 |
| 16 | 3,260 | 7299 |
| 17 | 3,511 | 7862 |
| 18 | 4,499 | 10074 |

Искәрмә: җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (оклады) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1 – 2 разрядка түбәнрәк итеп билгеләнә.

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2011 ел, 14 июнь, 477 нче
карарына 3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 30 октябрь, 812 нче
карары редакциясендә)

Хезмәт өчен түләүләре Бердәм тариф челтәре нигезендә хисаплап чыгарыла торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренә компенсация түләүләре күләмнәре

| Бердәм тариф челтәренең хезмәт өчен түләү разрядлары | Компенсация түләүләре, сум |
|---|---|
| 1 | 1803 |
| 2 | 1703 |
| 3 | 1613 |
| 4 | 1502 |
| 5 | 1225 |
| 6 | 1200 |
| 7 | 1124 |
| 8 | 1112 |
| 9 | 1112 |
| 10 | 1100 |
| 11 | 1093 |
| 12 | 1093 |
| 13 | 1093 |
| 14 | 1093 |
| 15 | 1093 |
| 16 | 1093 |
| 17 | 1093 |
| 18 | 1093 |

______________________________________